| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>СТАРОДРОЖЖАНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ ЧҮПРӘЛЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.06.2021 г. Иске Чүпрәле авылы № 65

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә керми торган яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Урман кодексы нигезендә, Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы», «Әйләнә-тирәлекне саклау турында» 10.01.2002 ел, № 7-ФЗ Федераль закон, Иске Чүпрәле авыл җирлеге Уставы, Чүпрәле районы прокуроры таләбен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Башкарма комитетының 04.02.20021 ел, № 33 карары белән расланган «Татарстан Республикасы авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә керми торган яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы Нигезләмәгә» түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**а) 3.5 пунктна «өч көн эчендә» дигән сүзләр өстәргә;**

**б) 3.11 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.11. Агач кискән өчен түләүне башкармыйча гына, агач һәм куакларны кисү Чүпрәле муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан түбәндәге очракларда рөхсәт ителә:».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Башкарма комитет җитәкчесе: В.М.Салахутдинова